**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 12 октябрь № 737

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 22 декабрь, 912 нче; 2010 ел, 19 июль, 577 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 февраль, 88 нче; 2012 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 21 март, 196 нчы; 2013 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2013 ел, 28 июнь, 446 нчы; 2013 ел, 29 август, 612 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2014 ел, 1 март, 133 нче; 2014 ел, 18 апрель, 255 нче; 2014 ел, 8 октябрь, 742 нче; 2015 ел, 22 гыйнвар, 28 нче; 2015 ел, 9 февраль, 72 нче; 2015 ел, 6 июль, 490 нчы; 2016 ел, 30 апрель, 269 нчы; 2016 ел, 9 июнь, 382 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктка «(алга таба – дәүләт предприятиеләре)» сүзләреннән соң «, милекче вәкаләтләре Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш»;

3.3 пунктта:

3.3.29 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.29. Законнарда билгеләнгән тәртиптә төзелә торган дәүләт предприятиеләренең, милекче вәкаләтләре Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш, гамәлгә куючысы була. Дәүләт предприятиеләренең, милекче вәкаләтләре Татарстан

Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш, уставларын раслый.

Дәүләт предприятиеләренең устав фондын формалаштыра, үзгәртә, шулай ук аларның резерв һәм бүтән фондларыннан файдалануны тикшерүдә тота, милекче вәкаләтләре Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш.»;

3.3.30 пунктчаның беренче һәм икенче абзацларына «, милекче вәкаләтләре Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш» сүзләрен өстәргә;

3.3.32 пунктчада:

беренче абзацка «дәүләт предприятиеләре» сүзләреннән соң «(милекче вәкаләтләре Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш)» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацка «, милекче вәкаләтләре Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш» сүзләрен өстәргә;

3.3.33 пунктчага «, милекче вәкаләтләре Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш» сүзләрен өстәргә;

3.3.36 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.36. Татарстан Республикасы казнасының күчемсез һәм күчемле мөлкәтне саклауны һәм максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны, Татарстан Республикасы милкендәге, законнарда билгеләнгән тәртиптәге хокукларда дәүләт предприятиеләренә беркетелгән, шулай ук билгеләнгән тәртиптә бүтән затларга бирелгән җир кишәрлекләре һәм бүтән мөлкәт белән, милекче вәкаләтләре Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш, дәүләт учреждениеләре, шулай ук тарафыннан идарә итү, ия булу, эш итү, билгеләнеше буенча файдалану һәм саклауны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра һәм бозулар билгеле булганда законнар нигезендә аларны бетерү һәм гаепле затларны җаваплылыкка тарту өчен кирәкле чаралар күрә.»;

3.3.41 пунктчада:

беренче абзацның беренче җөмләсенә «, милекче вәкаләтләре Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацка «дәүләт предприятиеләрен бетерү» сүзләреннән соң «, милекче вәкаләтләре Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш» сүзләрен өстәргә;

3.3.42 пунктчага «дәүләт предприятиеләре» сүзләреннән соң «, милекче вәкаләтләре Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш,» сүзләрен өстәргә;

3.3.44 пунктчаның беренче абзацына «, милекче вәкаләтләре Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш» сүзләрен өстәргә;

3.3.63 пунктчаның беренче абзацына «дәүләт предприятиеләре» сүзләреннән соң «, милекче вәкаләтләре Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш,» сүзләрен өстәргә;

3.3.68 пунктчада «(бирелгән дәүләт вәкаләтен гамәлгә ашыру сыйфатын чагылдыра торган индикаторлар билгеләү һәм индикаторлар мәгънәләренә ирешүне тикшерүдә тоту юлы белән)» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.3.69 пунктчага «дәүләт предприятиеләре» сүзләреннән соң «, милекче вәкаләтләре Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш,» сүзләрен өстәргә;

3.3.71 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.71. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тиешле органнары белән килешү буенча Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләрен (алга таба – җитәкчеләр) сайлауны, вазыйфага билгеләүне, биләгән вазыйфасыннан азат итүне гамәлгә ашыра, җитәкчеләре белән хезмәт шартнамәләренең гамәлдә булу вакытларын билгели, милекче вәкаләтләре Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш.

Җитәкчеләр белән хезмәт шартнамәләрен төзү, үзгәртү һәм өзүне (шул исәптән элек тармак министрлыклары һәм ведомстволары белән төзелгән), законнарда билгеләнгән тәртиптә хезмәт шартнамәләре шартларын үтәүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш.

Дәүләт предприятиеләренең баш хисапчыларын эшкә алуны, алар белән хезмәт шартнамәләрен төзү, үзгәртү һәм өзүне килештерә, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш.»;

3.3.72 пунктчага «дәүләт предприятиеләре» сүзләреннән соң «, милекче вәкаләтләре Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш,» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.99 һәм 3.3.100 пунктчаларын өстәргә:

«3.3.99. Законнарда билгеләнгән очракларда реклама корылышларын урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына сатулар оештыра һәм үткәрә, реклама корылышларын урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзи.

3.3.100. Ясалма җир кишәрлеген булдыру турында шартнамәләр төзү хокукына аукционнар оештыра һәм үткәрә, Ясалма җир кишәрлеген булдыру турында шартнамәләр төзи, «Федераль милектәге су объектларында булдырылган ясалма җир кишәрлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 19 июлендәге 246-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 1 өлешнең 2 пунктында каралган очракта ясалма булдырылган җир кишәрлекләренә Татарстан Республикасы милек хокукын теркәүне гамәлгә ашыра.»;

4.1пунктның 4.1.8 пунктчасында:

өченче абзацка «дәүләт предприятиеләре» сүзләреннән соң «, милекче вәкаләтләре Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш,» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацка «, милекче вәкаләтләре Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш,» сүзләрен өстәргә;

5.2 пунктның унберенче абзацына «дәүләт предприятиеләре җитәкчеләре» сүзләреннән соң «, милекче вәкаләтләре Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш,» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 5.4 пункт өстәргә:

«5.4. Министрлыкның структур бүлекчәләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү министр боерыгы белән расланган нәтиҗәлелек күрсәткечләре исемлеге нигезендә гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\737.docx